ISSN 0868-8001 16+
№ 10 (1118) / 2024

# Мәгариф education



■ Рәмис МӨҖИПОВ: «Күзәтү органнарыннан куркырга кирәкми»

■ Быел иң яхшы туган тел укытучысы – Бурятиядән

■ Баулы районы мөгаллимнәре презентациясе

## Даринә Ганиева:

# «Һәр яңалык – безнең өчен яңа мөмкинлек»

podpiska.pochta.ru



»

**Ләйлә Гарифҗанова турында тулырак «Мәгариф. Татар теле» электрон журналының 3 нче санында укый аласыз.**

> Осталыкта көч сынашу гына түгел, беренче чиратта милләтеңне, ана телеңнең матурлыгын, камиллеген күрсәтү һәм профессиональ яктан үсү дә.

якынлашып килгән мәктәпкәчә белем көне белән котлады.

Светлана Владимировна белән, ул туган ягы Улан-Удэга кайткач, «Җиңүчене ничегрәк каршыладылар?» – дип шалтыратып хәбәрләштем.

– Бурятия Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Батор Буянтуев, үзем эшләгән 1 нче лицей-интернат директоры Булат Шойнжонов зур хөрмәт күрсәтеп каршы алдылар, җиңүем белән ихлас котладылар. «Федераль бәйгене икенче елга үзебездә кабул итәбез, безгә Казанда алган тәҗрибәгез кирәк булачак», – диделәр. Бер сүз белән әйткәндә, Татарстаннан үз ана телем һәм бик мөһим миссия башкаруым белән горурланып, алга таба дәртләнеп эшләргә яңа сулыш алып кайттым, – ди Светлана Владимировна.

**ҮЗЕБЕЗНЕҢ ЛӘЙЛӘ**

Икенче урын җиңүчеләрен тәбрикләү өчен сәхнәгә РФ Президент идарәсенең эчке сәясәт буенча милли сәясәт департаменты җитәкчесе, жюри рәисе Татьяна Вагина һәм РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасы Милләтләр эшләре буенча комитеты рәисенең беренче урынбасары Илдар Гыйльметдиновлар күтәрелде. Бүләкләнүчеләр – Казанның 19 нчы гимназиясенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ләйлә Гарифҗа-

podpiska.pochta.ru

**– Даринә Зәйтүновна, мәгариф оешмаларының уку елына әзерлеген ничек бәялисез? Быел тормыш иминлеге нигезләре (ОБЖ), хезмәт дәресләренең заманчалаштырылуын, гаилә белеме дәресләре кертелүен, шулай ук телефоннарның тыелуын укытучылар һәм укучылар аңлап кабул иттеме?**

– Уку елы башлану – һәр гомуми белем бирү оешмасы өчен бик җаваплы этап. Белем бирү процессында катнашучыларның барысына да: педагогларга, укучыларга һәм ата-аналарга кагылышлы барлык мәсьәләләрне өйрәнеп фикер алышырга кирәк. Район комиссиясе тарафыннан мәгариф оешмаларын кабул итү – шундый этапларның берсе. Сүземне республика һәм район җитәкчелегенә, иганәчеләребезгә, ата-аналарыбызга, барлык мәктәп һәм балалар бакчалары җитәкчеләренә, укытучыларына һәм хезмәткәрләренә ихлас рәхмәт сүзеннән башлар идем. Белем көнендә талант һәм тырышлык нәтиҗәсендә, безнең барлык мәгариф оешмаларының да балалар һәм укытучылар өчен уңайлы, матур булуын күрдек. Быел да ашханәләргә һәм азык-төлек блокларына капиталь ремонт ясалды, Татар Кандызы һәм Татар Томбарлысы авылы мәктәпләрендә 19 млн сумга җиһазлар алыштырылды.

Дәрестән тыш эшчәнлек кысаларында укучыларның «Гаилә нигезләре» курсы барлыкка килде. Әгәр элегрәк җәмгыять белеме дәресендә гаилә мөнәсәбәтләре социаль һәм хокукый яктан гына каралган булса, «Гаилә нигезләре» кеше мөнәсәбәтләренең иң нечкә кылларына кагылырга тиеш. Миңа

**Педагогларның эмоциональ януын профилактикалау максатыннан яңа уку елында да укытучыларыбыз өчен тренинг элементлары булган чаралар циклы, тәҗрибә уртаклашу буенча чакырылган кунаклар белән очрашулар планлаштырылган.**

калса, мондый предмет мөһим һәм кирәк, чөнки барлык балалар тормышында да сәламәт гаилә мөнәсәбәтләре үрнәге юк, аларга киләчәктә үзләренә имин, бәхетле гаилә булдыру катлаулырак булачак. Мондый дисциплинаны кертүне күп кенә педагогик хезмәткәрләр яклый, бигрәк тә бу юнәлешләрне фән укытучылары, сыйныф җитәкчеләре, психологлар, социаль педагоглар хуплый.

**– Баулы районы – Казаннан иң ерак урнашкан районнарның берсе. Ара ераклыгы үзен сизderәме?**

– Баулы районының Татарстанның ерак читендә урнашуы уңайсызлыклар тудырса да, мәгариф системасының бер урында гына тормавын билгеләп үтү куанычлы. Без заман белән бергә атлыйбыз. Чөнки мәгариф инфраструктурасы, кадрлар сәясәте, укыту сыйфаты, сәләтле балалар белән эшләү, укучыларыбызга һөнәри юнәлеш

podpiska.pochta.ru




*Роза Николаевна Волкова, башлангыч сыйныфлар укытучысы*

алмый. Проектның максаты ачык, ягъни «Остазлык мәктәбе» үз алдына гимназиянең фәннәрне татар телендә укыту тәҗрибәсен республика һәм Россиядәге милли мәктәпләргә җиткерү, бергәләп тәҗрибә уртаклашуны күз уңында тота. Шул ук вакытта булачак укытучыларга (студентларга) практика лабораториясе вазифасын да башкарачак. Бу инде элегрәк төзелгән мәктәпнең тагын бер авырткан җиреннән кул китә дигән сүз: өч катлы корпуста урыннар – 12 кабинет, лабораторияләр, конференцияләр, спорт һәм тренажёр заллары, тавыш яздыру студиясе, күп функцияле мәйданчык – һәммәсе яңа мөмкинлекләргә юл ача. Шушында ук мәшһүр татар мәгърифәтчесе, фәлсәфәче, тарихчы, дин галиме, педагог, этнограф, көнчыгыш халыклар белгече Шиһабетдин Мәрҗани һәм нәкышче, сынчы, ТАССРның һәм РСФСРның халык рәссамы Бакый Урманчега багышланган музей да булачак, диләр.

**КУКМАРА**

Кукмараның 3 нче мәктәбендә дә яңа корпусның ачылуын түземсезлек белән көткәннәр. Чөнки моннан 50 ел элек 678 балага исәпләп төзелгән (3284 кв.м) мәктәптә бүгенге көндә 1065 бала белем ала, ике сменада укыйлар.

– Микрорайон елдан-ел үсә, шуңа яңа корпуска зур өметләр баглыйбыз. Төзүчеләр яңа корпусны ноябрь аенда өлгертеп файдалануга тапшырсалар, чын-чынлап иркенәячәкбез.

Анда 22–25 кешелек уку кабинетлары, логопед, ана телебезне һәм чит телләрне өйрәнү өчен кабинетлар, шулай ук озайтылган көн төркемендәге балалар өчен уен бүлмәсе, кече сыйныфлар өчен китапханә, спорт залы, 188 урынлык ашханә һәм 228 урынга актлар залыбыз булачак, хәтта лифт эшләячәк, – ди мәктәп директоры **Диләрә Хәкимова**.

**ПИТРӘЧ**

Питрәч районы Көек авылы «Алгоритм» технологик лицееның яңа

podpiska.pochta.ru

# О ПЕРВЫХ ТАТАРСКИХ БИБЛИОТЕКАХ

**СВЕДЕНИЯ ОБ АВТОРЕ:**

**Лилия Рамилевна ГАБДРАФИКОВА** – кандидат исторических наук (2008), доктор исторических наук (2013), профессор АН РТ (2024). Область научных интересов – социальная история Российской империи, история городской культуры XIX – начала XX вв., история татарского народа и народов Поволжья.
Автор более 150 научных работ по истории татар и Татарстана, Волго-Уральского региона, в том числе 6 монографий. С 2009 года работает в Институте истории имени Ш. Марджани АН РТ, а также с 2021 года – в Казанском научном центре РАН.



Фото из личного архива

Конец XIX – начало XX века по праву считается временем расцвета татарской буржуазной культуры: с книжными издательствами и массой периодических изданий. Благодаря им образовалось единое информационное пространство, которое объединяло татар из разных уголков Российской империи. Немалую роль в этом сыграли первые татарские библиотеки.

## ПЕРВАЯ ЧИТАЛЬНЯ

Высокая культура чтения, огромное уважение к книге являлись частью менталитета татарского народа. Умение самостоятельно читать Коран было долгом каждого правоверного мусульманина. Родители отправляли своих детей в медресе или к абыстай (супруге муллы) прежде всего для того, чтобы их научили читать священную книгу мусульман. Богатые домашние библиотеки имелись не только у представителей духовенства и интеллигенции, но и в купеческих семьях. На рубеже XIX–XX вв. в домашних библиотеках татарских семей, наряду с религиозной литературой, росла доля светских книг.

Распространению культуры чтения газет и журналов, а также светских книг в немалой степени спо-

podpiska.pochta.ru

# What is tolerance?

**(Урок английского языка по формированию межкультурной и коммуникативной компетентности в 10 классе)**



**Дина ХУСНЕТДИНОВА,**
учитель английского языка первой квалификационной категории многопрофильной школы № 181 города Казани

**Цель:** сформировать представление о том, что каждый может внести свой маленький вклад в решение проблем межнационального взаимодействия.

**Задачи:** акцентировать внимание учащихся на проблемах межнационального взаимодействия; развитие умений и навыков поиска решений проблемы, систематизации и анализа полученной информации; развитие умений групповой и дискуссионной работы.

**Техническое обеспечение:** проектор, экран, компьютер.

**Предполагаемый результат:**
– *личностный:* убеждаются в том, что толерантность – основа межнационального взаимодействия; осознают ответственность за свои действия и важность минимального вклада каждого в решение проблемы;

– *метапредметный:* умеют оценивать информацию; выявляют и анализируют различные мнения о проблеме; аргументируют свою точку зрения;

– *предметный:* совершенствуют навыки диалогической речи по теме «толерантность».

**ТЕХНОЛОГИЧЕСКАЯ КАРТА УРОКА**

| Этап занятия | Деятельность учителя | Деятельность учащихся | УУД |
|---|---|---|---|
| Мотивация к учебной деятельности. (4 мин.) | Учитель задает вопросы:<br>1) Do you have friends of different nationalities?<br>2) What is friendship?<br>3) What is tolerance? How is it different from friendship? | Отвечают на вопросы учителя. | *Коммуникативные:* умение выражать свои мысли, строить речевые высказывания. |

podpiska.pochta.ru